Күренекле фольклорист, телче, тюрколог, педагог, язучы Нәкый Исәнбәтне иң борчыган мәсьәләләр – телебез, милли культура һәм әдәбиятыбызның язмышы, киләчәктә, җир йөзендә күпме милләтләр һаман милләт һәм халык булып яшәгәндә, татар халкыбызның дөньяда булу-булмавы. Абруйлы галим дөньяда үз милли теле, мәктәбе булмаган һәм үз туган ана телен бөтенләй белмәгән кешеләр – халыклар – дөньяда халык булудан туктаган халык, иң бәхетсез, культурасыз, мәдәниятсез халык дип санаган. Нәкый Исәнбәт Башкортстандагы күпкырлы эшчәнлеген татар һәм башкорт мәктәпләре өчен «Яшь буын» исемле әлифба дәреслеге язудан башлап җибәргән. Даут Юлтый белән бергәләп мәктәпләр өчен әдәбияттан калын хрестоматия төзеп чыгара. Нәкый Исәнбәт – латин графикасы буенча дискуссияләрдә актив катнашкан галим. Башта ул – «латинчы», тора-бара «гарәп»челәр төркеменә күчә. Яңа татар орфография проекты Х. Курбатов тарафыннан 1955 елда төзелә. Ул 1958 елны киң җәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим ителә. Нәкый Исәнбәт әлеге проектка карата фикерләрен «Совет Татарстаны» газетасында бастырып чыгара. 1995, 2015 елларда дөнья күргән «Татар грамматикасы»ның 1 томында бу мәкалә турында мәгълүмат китерелми. Бу җитди хезмәт программа характерында язылган, әлегә кадәр актуальлеген югалтмаган һәм тиешенчә бәяләнмәгән. 1958 елда Яңа орфография проектын хөкүмәт комиссиясе, җитешсезлекләре булу сәбәпле, гамәлгә ашырырлык дип тапмый. Бу карарга Нәкый Исәнбәтнең позициясе дә йогынты ясамый калмаган. Тел галимнәре хәзерге татар офографиясендә татар сүзләренең аерым төркемнәрен дөрес язу юнәлешендә кайбер проблемалар һәм каршылыклар булуын таныйлар. Абруйлы галимнең бу өлкәгә караган фикерләре бүген дә файдалы булыр дип, без Нәкый Исәнбәтнең әлеге мәкаләсен яңадан бастырырга булдык.



**Төп төшенчәләр:** тюркология, татар тел белеме, алфавит, орфография, Нәкый Исәнбәт

**Сылтама өчен:** Исәнбәт Н. Хәреф һәм имлабызның гыйльми нигезләре хакында // Tatarica. 2025. № 1 (24). 20–33 б. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-24-1-20-33


[1] Бу мәкалә 1958 елның 14 октябрендә «Совет Татарстаны» газетасында басылып чыкты [1], ләкин 1995, 2015 елларда дөнья күргән «Татар грамматикасы»ның 1 томында аның турында мәгълүмат китерелми. *Кар.*: [2], [3]. Автор вафат

– Тагын алфавит, тагын орфографияме?...[2]

Соңгы 50 ел эчендә халкыбыз берничә әлифба, күп санда проектлар, реформалар кичергәнгә, бу эшкә курку катыш карыйлар һәм шундый сорауны бирәләр икән, бу бер дә гаҗәп түгел. Бер без генә түгел, Ватаныбызның барлык төрки халыклары рус хәрефен кабул итте. Ләкин берсе дә хәреф һәм имла белән бездәге кадәр җәфаланмый. Әйтик, күршебездә генә башкортлар, казахлар, бер кабул иткән буенча бара бирәләр. Ни өчен бер безнеке генә болай яраксыз булып чыга сон? Ярый ла ул бу проект белән генә төзәлсә!

Чыннан да, иске хаталарны кабатламас, яңаларын булдырмас өчен, элекке һәм яңасының кайбер нигез якларына, принцип аермаларына кагылып үтәргә кирәк.

Мин үзем «Иман шарты» дип йөртелгән «Әлепби» китабыннан хәреф танырга өйрәндем[3]. Анын беренче битендә 29 гарәп хәрефе күрсәтелгән, аннары кыскарак аерым бер юлга **п, ч, ж, г, ң** дигән берничә үги хәреф өстәлгән иде. Димәк, әлепби нигездә гарәп графикасы һәм фонетикасы буенча төзелгән, шул хәрефләр койрыгында күрсәтелгән әлеге берничә хәреф кенә безгә аның буенча «төрке танырга» хезмәт итә иде. Билгеле, ул заманда татар дөньясында әлепбине чын татар әлифбасына әйләндерү өчен гаять зур, даулы көрәш барды. Бигрәк тә 1917 елдан соң, хәреф һәм имлабыз нык төзәтелде. Шулай да күңел һаман канәгатьләнерлек булмады. Яңалиф (латин) хәрәкәте башланды. Яңалиф моңарчы булган татар хәреф һәм орфографиясенең дөрес һәм кулае булып чыкты. Чөнки аның проектлары киң халык фикере һәм Үзәк белән киңәшеп, озак фикер алышканнан соң гына кабул ителде һәм төрки халыкларда аның унификация корылтае уздырылды.

1939 елда рус хәрефләрен кабул иткәндә[4], милли республикалар Үзәктән рус теле галимнәрен, тюркологларны да киңәшкә чакырдылар. Ул чакта Үзәктән рус теле галимнәрен, тюркологларны киңәшкә чакыру мәсьәләсе Казанда да кузгалды. Ләкин бездә: «Нигә аларны китереп мәшәкатьләргә, безнең үз тел галимнәребез дә җитәрлек» дип каршы киленде. Алардан башка эш ителде. Казанда ул чагында, чыннан да, безнең, уннарча тел галимебез, профессорларыбыз бар иде. Ләкин безнең хәреф һәм имлабызга, тел һәм грамматикабызга гаять дәрәҗәдә зарарлы йогынты ясаган маррчылык тәгълиматын тагын бер телгә алып үтмичә булмый. Һәммәбезгә мәгълүм: бу тәгълимат буенча тел үзе стадиаль рәвештә шартлап юк була да аның тузаннарыннан өченче бер яңа тел килеп чыга, милли телнең нигезе булган грамматика исә буш бер формаль нәрсә генә дип карала. Үкенечкә каршы, безнең тел галимнәребезнең барысы да диярлек бу зарарлы тәгълиматка дучар булган, хәтта күпчелеге турыдан-туры Марр[5] кул астында эшләгән кешеләр иде. Гамәлдәге әлифба[6] һәм орфографиябез алар тарафыннан төзелде[7]. Шунлыктан анда телебезнең фонетик һәм грамматик үзенчәлекләре нигезгә алынмады. Рус әлифбасы русча тәртибендә килеш алынды да койрыгына берничә хәреф өстәп куелды. Нигезе белән бу хәтта мин башта әйтеп үткән борынгы әлепбидән дә начар булып чыкты; анда ичмасам каты **къ, гъ**, кыска **вау** кебек хәрефләр бар иде. Монысында алар да калмады Алынма сүзләрдә график принцип дигән «нигез» алынды. Ягъни, ул сүзләргә татар теленең грамматикасы кануны йөрми, алар русча нигездә языла, дип куелды. Бу хәлләр бер әлифба эчендә ике әлифба саклау гына түгел, бер тел эчендә ике тел грамматикасы сакларга

булу сәбәпле, мәкаләнең структурасына, фәнни аппаратына редактор М. М. Хәбетдинова тарафыннан журнал таләпләренә туры китереп төзәтмәләр кертелде, мәкаләгә искәрмәләр төзелде.

[2] Сүз 1958 елда басылган Х. Р. Курбатовның «Татар теленең алфавит һәм орфографиясе: Проект»ы турында бара [4], [5].

[3] شرائط الايمان«Иман шарты» – Шараит ал-иман. [6]

[4] *Кар.*: Х. Курбатовның «Татар алфавитының һәм орфографиясенең тарихы»н [7].

[5] Николай Яковлевич Марр (1864–1934) – Россия һәм Совет көнчыгышны һәм Кавказны өйрәнүче, филолог, тарихчы, этнограф һәм археолог, Император фәннәр академиясе академигы (1912), СССР ФА академигы һәм вице-президенты, гуманитар һәм иҗтимагый фәннәр өлкәсендә безнең илдә гаять зур абруй казанган тел белгече.

[6] *Кар.*: [8], [9].

[7] Татарларда яңа алфавит һәм орфография 1939 елның 5 маенда рәсми рәвештә гамәлгә куела. Кулланылыш барышында кертелгән кайбер орфографик аныклаулар 1941 елның 10 гыйнварында раслана. Ләкин кирилл графикасы нигезендәге татар язуын камилләштерү омтылышлары моның белән генә тәмамланмый. 1955 елда яңа орфография проекты төзелә. Ул 1958 елны киң җәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим ителә, әмма хөкүмәт комиссиясе аны, җитешсезлекләре булу сәбәпле, гамәлгә ашырырлык дип тапмый.

тырышу иде. Шулай алсак, рус телен өйрәнү җиңел була дип ышандырсалар да, билгеле, гамәлдә эш киресенчә булып чыкты. Чөнки әлифба һәм орфография ни дәрәҗәдә үз телебез фонетикасы һәм грамматикасы нигезендә төзелсә, безгә рус телен өйрәнү шул хәтле җинел булачак. Чөнки ул үзенең аваз системасында рус әлифбасының функциясенә кереп эшне бутамаячак, һәр ике телнең хәреф һәм авазларын дөрес билгеләргә сәбәп булачак.

Хуш, инде бу яңа проектта эшнең бу ягы ничек тора соң? Ул кереш сүзендә фонетик принцип алынганын игълан итә һәм чынлап та без анда бу юлда бер-ике җитди адым ясалганын күрәбез: бик кирәкле **къ-гъ** хәрефләре алынган, әлифба койрыгында салган «саф үз» хәрефләребез дә әлифбада һәрберсе үз тәртибендә лаеклы урын алган. Кагыйдәләр арасында кайбер алынма сүзләрне татар әйтелешендә язу моментлары да өстәлгән.

Болары бик яхшы. Ләкин, үкенечкә каршы, проект шуннан ары күп уза алмаган, телебезнең фонетик нигезендә эзлекле була алмаган, элекке үк хаталарны яңа төстә кабатлауга юл калдырылган, шуны аклау өчен кагыйдәләр авырайтылган, аларга әллә ни хәтле искәрмәләр, чыгармалар ясалган.

Алыйк, мәсәлән, **ы** хәрефен: рус һәм татар сүзләре өчен аңа киң әйтелеш, тар әйтелеш дигән ике вазыйфа йөкләнә. Шулай да бу куелыш эшне коткармый. [**ый]** авазын язганда киң яки тар әйтелеш дигәнебез юкка чыга: **сыр (эремчек – сыйр), Насыйров (Насыров)** һ.б.

Иң эчне пошырганы бу **ы** хәрефенең берүзе ике хәреф урынын алуы (ул үзе дә ике хәрефтән – нечкәлек билгесе **ь** һәм **1** таягыннан тора). Безнең телнең сингармонизм кануны буенча бер үк сүз эчендә ул беррәттән 5–10 җиргә язылa: **былтыргысыныкының**, **кычкырыштырындырдыгызмыни**? Инде бер китап бите язсаң, анда йөзләрчә шундый нечкәлек билгеләре белән таяклар тезәргә туры килә. Бу эш гаҗәп дәрәҗәдә кулны тоткарлый, сүзнең ямен, язуның тәмен боза, җитмәсә, үзе дөрес язуга да ярдәм итми, **ы** урынына **ъ** билгесе алырга ясалган тәкъдимнәр дә эшне коткара алмый. Чөнки **ъ** ның үз вазыйфасы бар, аннары баягы **къчкъръштърдъгъзмъни** сүзен бу хәреф белән язып карасак, тагын да ипсезрәк нәрсә хасил булачак. Элекке яңалифтә **ы** ның нечкәлек билгесе формасында язылуы кыска һәм җиңел иде. Хәзерге әлифбада бу хәреф нечкәлек билгесе булып тора, димәк, аны икенче эшкә куша алмыйбыз. Шулай булгач, бу ике хәрефтән гыйбарәт булганының икенче яртысы булган таягын гына татар **ы**-сы итеп алып булмыймы? Мәсәлән, **чін, кір, Насійри**. Казахлар, кирәк булгач, **і** хәрефен дә алганнар. Ә безнеке үзе ноктасыз да, элекке яңалиф формасына да якын, койрыклар куясы да юк. Хәтта басма өчен яңа хәреф коярга да кирәкми, **г** хәрефен астын өскә әйләндереп басып була.

Аннары бу **ы** хәрефенең язылу урыннары бер дә анык түгел. Мәсәлән, Казахстан, Татарстан, *арслан* кебек сүзләрдә **рс, кс** кебек тулы иҗекләрнең сузыклары **ы** булса да язылмыйлар, шул ук вакыт **сыйнфы, борны, урны** кебек йотылмалы иҗекләрдә, ни өчендер, **сыйныфы, урыны** дип **ы** ны чыгарып язарга кушыла. Шул нигездә әдәби телебездә **анысы, монысы, тумыран, асыра** дип язуларга һәр җирдә очрыйбыз. **Е** хәрефе белән дә шундый ук хәл: *айрата, койрык, исме, жисме* кебек җыйнак кына сүзләрне *исеме, җисеме, аерата, аермачык, коерыгында* дип язулар һәм башкалар. **Юну** белән **юыну** дигән ике сүзебез бар һәм моңарчы кешеләр су белән юыналар иде, хәзер язуларынча, балта белән агачлар **юына** башлады. Әдәби телебез орфографиясе сүзләрне җиңел һәм җыйнак язу өчен көрәшергә тиеш. **Рак-рәк** кушымчалары алдында **ы-е** ишетелсә дә, аларны төшерәбез бит (**аграк, кызурак** һ.б.). Бәлки **тыру-терү** (**уйлаштыру, сөйләштерү**)ләр арасында да кыскарту кагыйдәсен кертеп булыр?

Ләкин бәхәснең кызуы анда түгел, бәлки **в, е, й, ы, ый, ю, я** хәрефләренең язылышы һәм аларга караган кагыйдәләр буенча бергә бара. Чөнки бу хәрефләрдә специфик рус авазлары белән татар авазлары бик нык чуалтыла. Бу җайсызлыктан чыгу өчен безгә ике үз хәрефебез җитми: кыска **вау** белән кыска **йе**.

Кыска **вау** турында иптәш Фасиевнең[8] элекке яңалиф **v** сын алырга тәкъдим итүе бик дөрес һәм урынлы. Шуның белән **у-ү, в** хәрефләрен төрлечә азаплаудан берьюлы котылабыз. Минемчә, тагын икенче бер уңайсыз хәлебездән чыгуда безгә кыска **йе** өчен яңалифтан **j** хәрефен алу яхшы булыр иде. Бу хәрефне алу әлифбабызда хәреф күбәйтү булмас, киресенчә, киметү булыр иде. Чөнки ул менә никадәр хәрефне бер үзе алыштыра ала:

**Я**: jәш, jam, jәм, баjа, бәjә, jака, jәдәч, гаjәт,
**Ю**: jука, jүкә, jуыну, өjү, тоjу;
**Й**: jозак, jөзек, тәj, тәjә, оjы, оjыj.

---

[8] *Иптәш Фасиев* – Фазыл Салих улы Фасиев (1925–2016), татар тел галиме, тәрҗемәче, филология фәннәре кандидаты.

**ь**: Төнјак, көнјак,

**ъ**: јылјазма, објектив,

**е**: (иҗек башында) јегет, јыл, тыјыл, ијел, тојылу, төјелү.

Безнең гамәлдәге орфографиябездә әлегә хәтле иң күп бәхәс һәм буталчык тудырганы да шул хәрефләр түгелмени? Әгәр дә без **j** хәрефен алсак, ул безне **ю, я, й, ъ, ь** һәм хәтта, өлешчә **е, ы** шикелле специфик рус хәрефләренә татар теле функцияләрен йөкләү җайсызлыгыннан берьюлы коткарыр һәм бу хәрефләрнең язылышы турында орфография кагыйдәләрен тутырган әллә ни хәтле искәрмә һәм чыгармалардан котылыр идек. Шуның белән телебезнең фонетик һәм сингармонизм үзенчәлеге дөрес чагылыр, **j** элекке яңалиф хәрефебез булганга, аны өйрәнү авыр һәм ят эш булмас, киресенчә, ул әлифбабызга милли колорит кына өстәр иде.

Бу урында бәлки безгә: ни өчен **j** урынына рус әлифбасындагы **й** хәрефен генә алмаска, диярләр. Ул хәреф рус графикасында рус алфавиты буенча бары тик сәкенле хәреф булып, исеме дә шуның өчен краткий дип атала. Шунлыктан, бер вакытта да сүз һәм иҗек башында килә алмый, катлаулы хәреф булып, алдан кушып язуга бик җайсыз.

**V** һәм **i** хәрефләре алу аркасында безгә киләчәктә **в, ю, я, ы, й, ь, ъ** хәрефләрен безнең әлифбадан кыскарту, аларны махсус рус алфавиты өчен калдыру мөмкинлеге ачыла. Ул хәрефләрне безнең балалар рус телендә махсус үтәрләр һәм бу авазларның функцияләрен безнеке белән чуалтмыйча дөрес өйрәнерләр иде. Теләгәндә, **ц, щ** хәрефләрен дә кыскартып булачак. **Революция, социализм** кебек бер-ике сүзне **тс,** ***v*** аша язудан дөреслек һәм мәгънәләренә кимчелек килмәс, формасы белән дә халыкара язылышларына якынрак килү булачак, щ**и** белән **щетка** кебек ике сүз өчен үзебезгә аерым хәреф тотуның кирәге юк, үз хәрефләребез белән дә яза алырбыз.

***

*Ул спортивная команда белән художественное училищедан кайтышлый общая столоваяга кермәкче булды. Ләкин анда ябык булгач, Казанская гостиницага кереп, аның мраморная заласында рижская креслога утырып, папиросасын кабызып җибәрде...*

Шулай язсак, билгеле, моны беркем дә татарча дип әйтмәс, бәлки телнең грамматик төзелешен һәм димәк, үзен нигездән җимерә торган мондый ясалма җөмләләр уйлап чыгарганыбыз өчен бездән көләрләр иде. Ләкин әдәбиятыбызның алдынгы үрнәге итеп йөртелгән һәм мәктәпләребездә үтелгән кайбер әсәрләрдә шундый һәм шуңа охшашлы җөмлә әйләнешләренә очрамыйбызмыни? Мәсәлән, К. Нәҗминең «Язгы җилләр»ендә:

«*Юнкерское училищены бетергәч, атасы аны учебная команда офицеры итеп калдырды»; «хәзергә общая камера торып тор», «Бүген әле ул офицерское собраниедән тиз генә бушый алмас»; «Генерал от инфантерии Сандицкий*» һ. б.

Бу рәвешле саф рус теле грамматикасы нигезендә «татарча», әдәби язулар безгә каян килә соң? Нигез кайда? Моңа «законный нигезне» безгә Мөхәммәтхан агалар ясап биргән гамәлдәге орфография биреп килде[9]. Чөнки ул телебезнең үз фонетик принцибында төзелмәү генә түгел, морфологик-грамматик принцибында да төзелмәгән, анда алынма сүзләр русча баш килештә һәм хәтта мужск., средн., женск. родлары сакланган хәлдә алырга кушылган. Имла һәм әдәби телебезгә торгынлык китергән, бүген хәреф һәм орфографиябезне яңадан кайтып карарга мәҗбүр иткән төп һәм җитди бер кимчелек тә шунда.

Хуш, инде яңа проект бу нигез мәсьәләдә нинди юл тота, аны ничек хәл кыла, алынма сүзләр ничек языла? Сүз башыннан күренүенчә, ул принципта татар теленең грамматик үзенчәлекләре буенча барырга вәгъдә бирә, аннары русчадан кергән сүзләр тамыр һәм нигез өлешләрендә рус орфографиясендәгечә языла, дип чикләүсыман бер нәрсә ясый. (§ 27).

Ләкин проект бу вәгъдәсен тиешенчә үтәми, бәлки график принцип дигән «нигез» белән телебезнең грамматик нигезен җимерә. Кушымчалар язылышына килеп җиткәч тә, ул русның именительный падежын һәм хәтта аның җенес төсмерләрен саклауны тагын татар теленә кагыйдә итеп кертә, **секретарьга, промышленностьтан, поезддан, подъезддан,**

[9] ***Мөхәммәтхан Әшрәфҗан улы Фазлуллин*** (1883–1964) – тюрколог, педагог, филология фәннәре докторы, профессор (1930), РСФСР һәм Татарстан АССРның атказанган фән эшлеклесе, РСФСР педагогика фәннәре академиясенең мөхбир әгъзасы (1950). 1930нчы елларда галим татар теленең орфографиясе, пунктуациясе, методикасы мәсьәләләре буенча җитди тикшеренүләр алып бара. Кар.: [10], [11].

**металлда, граммлы, Свердловск** һәм башкалар (§ 49, 50 һ. б.).

Димәк, бу кагыйдәләр буенча без һаман үз телебездә русча баш килеш һәм родлар ясап, **участок, участокта, судно, суднодан, промыселда, туфлялар**, **марлялар**... дип язуда дәвам итәчәкбез. Ләкин татар болай сөйләми бит. Ул: **учаскыда, промыслода** дип сөйли. Классик әдәбиятыбызча алсак, *промысла* дип язылa (*Ш. Камал*). Болай сөйләү русча белмәүдән түгел, бәлки телебезнең морфологик төзелеше шулай сөйләвебезне таләп иткән өчен.

Әллә бу алынма сүзләрдә баш килешне саклау рус морфологиясенә нигезләп алынамы? Мәсәлән, русчада баш килеш **участок** булса, калган күпчелек төрләнешендә **участки, участках, участке**... һ. б. килә. Татар халкы алынма сүзләрдә һич тә русчадагы баш килешкә таянмый, бәлки аның шул күпчелек формасын ала да, үз грамматик формасына буйсындырып төрләндерә. Шул нигездә **учаскысында, промыслысында, промышленностан**, **поездан** дип сөйли. Шулай булгач, татар орфографиясенә алынма сүзләрне русчадагы именительный падеж формасын саклаган хәлдә төрләндерергә дип кагыйдә куярга нинди нигез бар? Һич юк. Моны татар гына түгел, үз теле өчен руслар үзләре дә эшләгәне юк. Әмма алынма сүзләр белән ничек эш итүне безгә руслардан өйрәнергә бик ярый. Мәсәлән, алар татарның *баш* дигән сүзен алсалар, бу сүзнең татарча баш килеше ничек икән дип эзләп яки сорап тормыйлар, иң элек бик әйбәтләп тотып, аны хатын-кыз женесенә әйләндереп, **«Башка»** ясыйлар, аннан соң гына алалар. **Казань** дигәндә дә шундый бер хикмәт эшлиләр. Чөнки рус теленең милли үзенчәлеге, грамматик строе, тел сөреше шуны таләп итә. (Чөнки аның үзенең **голова** сүзе женский родта ясалган). Әмма татар телендә женес кушымчалары нигездә булмаганлыктан, аның телен көчләп женесле ясар хәл юк. Шунлыктан аның язуында **туфлялар, марлялар**, яки **марлялы** кул дигән кебек тел гариплеге һәм женесләмәләр була алмый, бу аның сингармонизмына да туры килми.

**Металл, грамм, класс** кебек сүзләр актыгында куш хәреф язарга кушыла. Дөрес, **металлылык, классыз** дигәндә татарча да куш хәреф килеп чыга, ләкин мондагы **лы, лык, сыз** дигәннең **лы, с** лары татар кушымчасыныкы, алар төп сүзнеке була алмыйлар. Димәк, бу кагыйдә буенча эзлекле барганда, мондый сүзләрне морфологик төрләнештә **класссыз, металллылык** рәвешендә өчәр куш хәреф белән язарга тиеш булыр идек. Ләкин кагыйдә безгә бу чагында икешәрне генә язарга куша. Ул чагында башта язарга дип куелган икешәр **лл**, икешәр **сс** ның берәрсе кая китә? Инде шул сүзләрне **металы, металына, металының, класының, класына** дип төрләндерсәк, тагын берәр **л** белән **с** юкка чыга. Шулай итеп, рус графикасын күпме генә сакларга тырышсак та, бара торгач бу сүзләрдә өч **л** дан икегә, аннары икедән бергә калды. Ни өчен? Чөнки телебезнең грамматик кануны буенча мондый сүзләрнең баш килеше актыгында куш хәрефләр була алмый. Әмма рус теленең баш килеше дә куш **мм, сс, лл** лар белән бетә ала. Чөнки рус теле буенча морфологик төрләндереп карасак, анда куш хәреф ятканы ачыла: **металла, металлах** һ. б. Димәк, проектта бу кагыйдә рус теле морфологиясеннән килеп керә.

Шунысы да кызык: шулай алынма сүзләрдә юкка чыккан **лл, сс, мм, сть** кебек хәрефләрне бар җирдә дә саклыйбыз дигәнче, үз телебездә чыннан да бар булган **ст** лар юкка чыгып куя! Мәсәлән, проект безгә **ас, өс, дус** дип язарга куша (§ 32, искәрмә 5). Ләкин шул сүзләрнең **астын өскә** китерсәң, **астның т** сы килеп чыга, **өстен аска** китерденме – **өстнең т** сы килеп чыга... Димәк, бу сүзләрнең төбендә **т** лар посып ята, телебезнең морфологик төрләнеше безгә аларны күрсәтеп тора, шунлыктан аларны язарга нигезебез бар. Әмма грамматикабыз тапмаган җирдән аларны бездән таптырырга нигез юк. Рус телен белдерү өчен дисәк, анысын рус грамматикасы үз өстенә ала, падежларны үткәндә балалар эшнең нидә икәнен бик тиз күрәчәкләр.

Проектта ай исемнәре русча һәм баш килештә язылулары да аңлашылмый. Әгәр дә бу исемнәрнең халыкара һәм интернациональ язылышлары шулай дип каралса, анысы да ялгыш, һәр халык бер үк латинча сүзләрне үз телләренчә үзгәртеп алганнар, руслар да шулай ук латинга да, башка тел законнарына да буйсынмаганнар (мәсәлән, **september** – **сентябрь**). Рус белән тугандаш телдәге украин, белорусларда да ай исемнәре латинча да, русча әйтелешендә дә алынмыйча, үзләренчә язылa. Татар халкы да ай исемнәрен үз телләренең законнарына буйсындырып, үзенчә әйтә: **гыйнвар, фибрал, март, апрыйл... синтәбер, дикәбер** һ. б. Шунлыктан мондый сүзләрне:

**январе, феврalendә, сентябрьдә** дип язулар безнең телдәгечә була алмый. Мондый язулар русча баш һәм предложный падеж кушымчаларын (**январь, в январе** формаларын) татар телендә куллану күренеше дип карарга кирәк. Ләкин юкка бу азап! Татар аны алай әйтми, руска моның кирәге юк. Бу эштән ике телне дә дөрес өйрәнүгә комачау гына килеп чыкканы һәммәбезнең күз алдында.

Бу уңай белән нигездә татарныкы булган кайбер сүзләрне бездә рус фонетикасына буйсындырып язуларны да кагыйдә белән аныклауга хаҗәт күрелә. Мәсәлән, *артель* сүзенең татарныкы булуы сүзлекләрдә һәм Энгельс хезмәтләрендә дә күрсәтелгән. Татар аны **әртил** дип сөйли: **әртил башыннан түләнә; баржаны бушатырга әртил белән ялландык** һ. б. Хәтта **ыштан** дигән ике иҗекле сүзебезне хәзер русча **штан** итеп бер иҗектә язалар. Ләкин русның **штан** дигәне татарның эчке киеме түгел, ахрысы. Алайга киткәч, аның балагын да безгә **штанина** дип алырга кала түгелме сон? Яки – **караул**, кычкыра дип язуларны алып карыйк. (Бу үз сүзебезне **каравыл** дип язарга кагыйдә булгач, аның кычкыруы да татарча булырга тиешледер?

Шул рәвешле, телдә сингармонизм дисәк тә әллә кайчан телебезгә кереп халыклашып беткән кайбер гарәп сүзләрен дә гарәп әйтүенә буйсындырып язарга тырышабыз. Халык **сәхрә**; ди; **әлбиттә, әдәм, пигамбәр, сурәт, фирештә, тәбигат, махсүс, шәхыс** дип сөйли. Язмада исә, хәтта шул кагыйдә китабының үзендә үк шундый сүзләрне гарәп орфографиясенә буйсындырып: **сахра, әмма, әлбәттә, адәм, пәйгамбәр, сурәт, фәрештә, табигать, махсус, шахыс** дип язып азапланабыз. Мең ел буе карныбызда йөргән шул сүзләрне әле булса үзебезнеке итеп сеңдерә алмыйча, үз телебездән үгәйсетеп язулар нигә кирәк? Бездә дә халыклашкан сүзләрдә, аның нигезе үз телебезнең нормасында язу булырга тиеш. Бу юлда проект кыюрак атларга, мисалларны да күпләбрәк китерергә тиешле.

**Ук, үк** кисәкчәләрен аерым яздыру да аныклауны сорый. Бу кагыйдә буенча **шундук, баюк, андук, баштук, иртүк, кичүк** кебек тоташ сүзләрдә әлегә хәтле аерып яздырыла. Ләкин бу хәл күп вакытта язучылар белән редакторлар арасында тавыш тудыра. Чөнки монда әйтелеш һәм мәгънә ягыннан зур аермалар бар: **шундук килеп җит!** – дисәк, **шундук** дигәнебез вакытны (в момент дигәнне) аңлата: – **дәфтәрең өстәлдә, китабың да шунда ук ята** дисәк, **шунда ук** дигәнебез урынны белдерә һ. б. Шулай ук көчәйткеч кисәкчәләр турында **ап-ак** белән **аппак** сүзләренең икесен дә бер кайчы белән кыркырга ярамавын әйтергә кирәк. Болар икесе ике сүз.

*Тотса, китсә, кошчы* сүзләрендә **ц, щ,** ишетелсә дә, **тс, шч** языла дип күрсәтү (§ 20–21) бик сәер. Моны татар сүзен русча әйттереп карау күренеше димәсәк, башкача аңлап булмый.

57 нче параграфта фамилияләрне **ов, овага** бетерүләр мәҗбүри форма итеп куелган. Ләкин моңа карап без **Сибгать Хәким, Гали Халит** иптәшләрне үзләре теләмәсә көчләп **овка** бетерә алмабыз. **Тукай, Рәми, Нәҗми, Гыйззәт** кебек фамилияләрне дә онытырга ярамый.

**Томскидән Свердловскигә Омски аша килдем, аннан Троиски ерак түгел** дигәндә, баш килештә **Троицк, Свердловск**, яки **киоск, Бирск** дип язарга кагыйдә кую да шул ук үз телеңнең морфологиясеннән качу бәласе. Шуның өстенә үз телеңдә болай яздырулар татар баласының йөзен кызарта икәнен дә истән чыгарырга ярамый. Чөнки шул язылышта калганда балаларның аларга үзләреннән артык сузыклар кушып укымыйча хәлләре юк. *Идән, игә, идә* дигән яңа төрле кушымчалар ясарга телебездә бернинди дә нигез юк.

**Устав, состав, Фурманов, актив** кебек сүзләрне **уставы, составында**, **Фурмановыбыз, активы** рәвешендә тел әйләнгесез итеп язарга кушу, бу сүзләрнең төрләнешендә **в** ны сакларга тырышу бәласе булса кирәк. Татар телендә **ак, күк, мәктәп** кебек каты **къ, гъ, п** гә беткән сүзләр төрләнештә **акы**, **күке, тупы** дип язылмыйлар, авазларын һәм хәрефләрен алыштыралар, алынма сүзләрдән **техник, тип, принцип** кебек сүзләрне дә шул нигездә **техниге, тибы**, **принцибе** дип баш килешен үзгәртәбез, димәк, шул ук нигездә **устав**, **состав, актив** кебек сүзләрнең соңгы хәрефләре дә төрләнештә **ф** гә әйләнәләр: **устафы, состафында, Фурманофыбыз, актифы** рәвешендә языла дип кагыйдә куймыйча котыла алмыйбыз.

Кыскасы, проектта фонетик, грамматик принцип алынса да, кызганычка каршы, бу нигезләр сакланмаган. Төп принцип мәсьәләләрдә мондый принципсызлык имлабызның төзәлүенә нык комачаулый, фикер алышучыларның тел төбе дә проекттагы шул кимчелекләрне төзәтүгә юнәлгән. Бу уңай

белән бигрәк тә Г. Халит һәм К. Сабиров иптәшләрнең «Совет Татарстаны»нда ясалган чыгышлары игътибарга лаек[10]. Кушымчалар ялгауда татар теле законнарыннан читкә китүнең нигезсез эш икәнен күрсәтүләрендә алар баштанаяк хаклы. Чөнки имлабызда бу күренешләрнең әле булса сузылып килүе телебезнең нәкъ шул грамматик структурасын танымаска теләү бәласе. Хәреф һәм имлабызда төп кимчелекләрдән котылу безгә телебезнең шул фонетик-грамматик нигезләрен саклауда булачак. Тел гыйлемендә марксизм тәгълиматы өйрәтүенчә, телнең грамматик структурасы сакланмаса, тел үзе дә сакланмый, бетә. Шунлыктан да грамматик төзелеш – ул нигезләр нигезе. Проект әле шул нигездә торып, бик нык уйлану һәм тикшеренүгә мохтаҗ. Ул бу килешенчә кабул итәрлек түгел.

Монда яңа орфографиябезнең фонетик, грамматик принциплары хакында сүз барды. Ләкин хәреф һәм имла мәсьәләсендә үткәндәге бай тәҗрибәләребездән файдалану юлында тарихи-традицион принципны да онытырга ярамый. Мәсәлән, язуыбызны авырайткан **ый** хәрефенең урыннарын кыскартуда яңалифтә каты **к**, каты **г, х, һ, ч, ш, җ, ж** ләрдән соң **ый** урынына **и** язылыр дигән кагыйдә куелган һәм шуның аркасында уку-язуыбызда җыйнаклык туган иде. Хәреф һәм имлада һәр урында да авазларның нәкъ сөйләткәндәгечә тулы шәкелен, фото-фонографиясен бирергә тырышу – бу үзе бик примитив төшенү. Без һаман яңа алынма иҗекләр эзлибез, тәҗвитлибез, башка телләрнең орфоэпия нормаларын да имлада чагылдырырга тырышабыз. Әйтик, борынгы гарәп хәрефенчә, имлабызда бездә күпчелек һәм чыгыш кушымчаларының формасы берәр генә – **лр, ди** иде, 1905 нче елдан соң икешәр: **лар-ләр**, **дан-дән** булды, инде хәзер күпчелекне – дүрткә (**лар-ләр, нар-нәр**), чыгышны алтыга җиткердек (**дан-дән, тан-тән, нан-нән**). Сүз ахырында **п** язылмый, **б** языла иде: **калыб, калыбы, мәктәб-мәктәбе** һ. б., аны да **п** ясадык һәм шул орфоэпик нормалар кертүебезне камиллек санадык. Әмма шуның аркасында бүген **клуб, штаб, масштаб** кебек сүзләргә имлабызда аерым кагыйдә һәм искәрмәләр кертергә мәҗбүр булганыбызны сизмибез. Гыйльми грамматика нигезендә эш иткән һәрбер халык үз орфографиясен ишетелгәнчә язам дип, натурачылык белән шөгыльләнми, бәлки сүз төрләнешләрен гомуми һәм уртак бер кагыйдәләргә, уртак формаларга китерергә тырыша. Рус, көнбатыш, латин, гарәп телләре орфографиясе шулай эшләнгән. Бүген без яңадан чит тел грамматик формаларын да кертеп орфографияне авырайтмаска тиешбез, җиңеллек һәм кыскалык өчен яңалифтә табылган кайбер традицияләргә, формаларга күз салу да артык булмас, дип беләм.

Кыскасы, орфографиябезнең гыйльми нигезләре булмаганда, киләчәктә дә без имла һәм хәреф төзәтү бәласеннән котылмаячакбыз.

[10] *Кар.*: [12].

**Әдәбият**


1. Исәнбәт Н. Хәреф һәм имлабызның гыйльми нигезләре хакында // Совет Татарстаны. 1958. 14 октябрь. 3–4 б.
2. Татарская грамматика В 3 т.. Т. 1 / [М. З. Закиев, Х. Х. Салимов, Х. Р. Курбатов и др.]. [Репр. воспр. изд. 1993 г.]. 1995. 582 с.
3. Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М. З. Зәкиев; ред. Ф. М. Хисамова. Тулыландырылган 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. I. 512 б.
4. Курбатов Х. Р. Татар теленең алфавит һәм орфографиясе: Проект. Казан: Татар. кит. нәшр. 1958. 28 б.
5. Курбатов Х. Р. Татар теленең алфавит һәм орфографиясе: Проект // Совет мәктәбе. 1958. №3. 17–40 б.
6. شرائط الايمان Шараит ал-иман. Казан, 1900. 30 б.
7. Курбатов Х. История алфавита и орфографии татарского языка. Казань: Б.и., 1960. 130 б.
8. Gorbangəliev M. Əlifba. Kazan: Tatgosizdat, 1938. 77 b.
9. Фазлуллин М. Зурлар өчен әлифба. Казан: Таттосиздат, 1940. 95 б.
10. Фазлуллин М. А. Орфография принциплары. Казан : Татиздат, 1930. 68 б.
11. Фазлуллин М.А. Орфография укытуны яхшырту мәсьәләләре // Совет мәктәбе. 1952. № 2.
12. Халит Г., Сабиров К. Орфография проекты уңае белән // Совет Татарстаны. 1958. 18 май. 3–4 б.

# О НАУЧНЫХ ОСНОВАХ НАШЕГО АЛФАВИТА И ОРФОГРАФИИ[1]

**Наки Исанбет,**
mileuscha@mail.ru.

Известный фольклорист, языковед, тюрколог, педагог, писатель Наки Исанбет в ряде своих работ размышляет о судьбе татарской нации, стремится обозначить ее место в мире, а также выражает обеспокоенность состоянием родного языка, национальной культуры и литературы. Людей, не владеющих родным языком, живущих в стране, где нет национальных школ, ученый считает несчастными, малокультурными и невежественными. Осознавая всю катастрофичность данной ситуации, Наки Исанбет предсказал в недалеком будущем их исчезновение в национальном смысле. Свою творческую карьеру в Башкортостане ученый начал с создания азбук «Яшь буын» («Молодое поколение») для татарских и башкирских школ. Совместно с Даутом Юлтыем он выпустил в свет хрестоматию по литературе для учащихся. Наки Исанбет принимал активное участие в дискуссиях по латинице. Вначале он был на стороне «латинистов», затем перешел на сторону «арабистов». В 1955 г. Х. Курбатов разработал Проект новой татарской орфографии, представленный на суд общественности в 1958 г. Наки Исанбет поделился своим мнением о проекте в газете «Совет Татарстаны» («Советский Татарстан»). В «Татарских грамматиках» (1995, 2015) эта дискуссия не упоминается, а сама статья не включена в библиографию. Работа ученого носит программный характер и не утратила актуальности и поныне. До сих пор ученые в силу непонятных причин обходили ее вниманием. В 1958 г. государственная комиссия сочла Новый проект татарской орфографии несовершенным, поэтому он не был реализован в жизнь. Вне сомнения, рекомендации Наки Исанбета членами комиссии были услышаны. Современные лингвисты констатируют наличие в татарской орфографии определенных проблем и противоречий с написанием отдельных групп слов. Публикуя эту статью вновь, мы стремимся привлечь внимание ученых к ценным наблюдениям Наки Исанбета в сфере татарской орфографии.

**Ключевые слова:** тюркология, татарский язык, теория языка, алфавит, орфография, Наки Исанбет

**Для цитирования**: Исанбет Н. О научных основах нашего алфавита и орфографии // Tatarica. 2025. № 1 (24). С. 20–33. https://doi.org/ 10.26907/2311-2042-2025-24-1-20-33

[1] Эта статья была опубликована 14 октября 1958 г. в газете «Совет Татарстаны» («Советский Татарстан») [1], однако она не упоминается в «Татарских грамматиках», увидевших свет в 1995, 2015 гг. См.: [2], [3]. В связи с уходом из жизни автора, в структуру, научный аппарат статьи были внесены изменения редактором М. М. Хабутдиновой.